ГЛАВА АБСАЛЯМОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.2,
с.Абсалямово, 423957

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ӘБСӘЛӘМ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр урамы, 2 йорт,
Әбсәләм авылы, 423957

Тел.:(85593) 4-26-79, факс:4-26-79, e-mail: Absal..Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 2** **06 декабрь 2021 ел**

2022 елда Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендәге Әбсәләм торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы карарының 25.1, 56 санлы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, 2019 елның 17 июлендә 8 санлы карары белән кабул ителгән Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 14 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Әбсәләм авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2021 елның 18 декабрендә 11.00 сәгатьтә, Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Әбсәләм авылы, Совет урамы, 50Г йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасы янында 2022 елда Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегенең Әбсәләм торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Әбсәләм авыл җирлегендәге Әбсәләм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Әбсәләм торак пунктындагы Совет урамына асфальт салу (сатып алу, алып кайту, түшәү, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Әбсәләм торак пунктындагы Юл буе урамында су линиясе төзү (материаллар, җиһазлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү);
- Әбсәләм торак пунктында урам юлларын кардан чистарту, грейдерлаштыру (трактор өчен ягулык, запас частьлар сатып алу, эшләр өчен килешү нигезендә түләү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әбсәләм авыл җирлеге башкарма комитетына халык җыенына әзерлек һәм аны үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны Әбсәләм авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында кабул ителгән көннән 5 көн эчендә бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

Әбсәләм авыл җирлеге башлыгы Г.В. Кубашева